РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘР
СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2024 елның 7 августы № 24

Түбән Кама шәһәр Советының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Түбән Кама шәһәр Советы нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2021 елның 18 ноябрендәге 59 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләр үтәлешен муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

нигезләмәнең 2 нче кушымтасында 1 пунктны төшереп калдырырга.

2. Түбән Кама шәһәр Советының 2021 елның 18 ноябрендәге 60 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәре территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

нигезләмәнең 2 нче кушымтасында 1 пунктны төшереп калдырырга.

3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, шулай ук аны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының шәһәр инфраструктурасын үстерү буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры Р.Х. Муллин